ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.03.2022 Олы Кайбыч ав. № 168

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы 180 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы 180 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле бишенче абзацны өстәргә:

«- кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча

«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру-хокук бүлеге башлыгы Р.С.Шакировка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров